СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«12» декабрь 2024 ел** **№ 316**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы милкендәге хуҗалык алып бару хокукындагы яки оператив идарә итү хокукындагы муниципаль мәдәният оешмаларына беркетелгән мөлкәтне арендага тапшыруны килештерү тәртибен раслау турында**

«Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135–ФЗ номерлы Федераль законның $17^1$ статьясының $3^5$ өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 9 сентябрендәге 1529 номерлы карары белән расланган дәүләт яисә муниципаль мәдәният оешмаларына хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә карата аренда шартнамәләрен конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә генә төзү кагыйдәләренең 8 пункты нигезендә, Арча район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы милкендәге хуҗалык алып бару хокукындагы яки оператив идарә итү хокукындагы муниципаль мәдәният оешмаларына беркетелгән мөлкәтне арендага тапшыруны килештерү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
12.12 2024 ел, № 316
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы милкендәге хуҗалык алып бару хокукындагы яки оператив идарә итү хокукындагы муниципаль мәдәният оешмаларына беркетелгән мөлкәтне арендага тапшыруны килештерү тәртибе**

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының мәдәният оешмасы (алга таба – муниципаль мәдәният оешмасы) тарафыннан муниципаль мәдәният оешмасына хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәтен (алга таба – мөлкәт) муниципаль мөлкәтне гамәлгә куючы һәм милекче белән конкурслар яки аукционнар үткәрмичә генә арендага тапшыруны килештерү процедурасын билгели.

2. Муниципаль мәдәният оешмасы, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135–ФЗ номерлы Федераль законның $17^1$ статьясының $3^5$ өлеше, «Дәүләт яки муниципаль мәдәният оешмаларына хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә аренда шартнамәләрен конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә генә төзү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 9 сентябрендәге 1529 номерлы карары нигезендә, аренда шартнамәсе төзү кирәклеге турында гаризаны (заявканы) карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы мөлкәте милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы (алга таба – мөлкәт милекчесе), шулай ук гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы (алга таба – гамәлгә куючы) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына мөрәҗәгать итүчегә мөлкәтне арендага бирүне килештерү турында мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) җибәрә.

3. Мөрәҗәгатьтә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) фаразланган арендага алучының исеме, аның урнашкан урыны турында белешмәләр, почта адресы һәм элемтә телефоны номеры;

2) арендага тапшырырга тәкъдим ителә торган хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәт турында белешмәләр;

3) хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәтне арендага бирү аны нәтиҗәлерәк файдалануга ярдәм итәчәген нигезләү;

4) аренда шартнамәсен төзү тәкъдим ителә торган срок;

5) күздә тотыла торган арендага алучыны аңа мөлкәтне конкурс яисә аукцион уздырмыйча гына арендага бирү өчен сайлауны хокукый нигезләү:

а) арендатга алучының мөлкәткә ихтыяҗы, мөлкәттән файдалануның күздә тотыла торган максатлары;

б) килүчеләргә һәм муниципаль мәдәният оешмасы хезмәткәрләренә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә, сатуга тәкъдим ителә торган продукция һәм товарлар ассортименты турында мәгълүмат– җәмәгать туклануы оешмалары өчен;

в) сувенир, нәшрият һәм аудиовизуаль продукция ассортименты турында мәгълүмат – ваклап сату белән шөгыльләнүче юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен.

4. Мөрәҗәгатькә түбәндәге документлар кушып бирелә:

1) мөлкәтне арендалау шартнамәсе проекты;

2) аренда түләвенең базар бәясен исәпләү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән хисап (тәкъдим итү датасына 90 көннән дә артмаган вакыт белән);

3) сувенир, нәшрият һәм аудиовизуаль продукцияне ваклап сатуны гамәлгә ашыручы күздә тотылган арендага алучының (җәмәгать тупланувы оешмасының, юридик затның яисә шәхси эшкуарның) гаризасының күчермәсе;

4) шәхесне таныклаучы документның күчермәсе һәм шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (вакыты 30 көннән артмаган) - шәхси эшкуарлар өчен;

5) юридик затларың бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (вакыты 30 көннән артмаган) – юридик затлар өчен.

5. Муниципаль мәдәният оешмасына мөрәҗәгать итүчеләрдән мөлкәтнең бер төрен (төрләрен) арендалауга карата ике һәм аннан күбрәк гариза кергән очракта, мөрәҗәгать гаризалар кергән көннән чыгып чиратлылык тәртибендә җибәрелә.

6. Муниципаль мөлкәт милекчесе һәм гамәлгә куючысы мөрәҗәгатьне һәм аңа кушып бирелгән барлык документларны алар кергән көннән алып 30 эш көне эчендә карый һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) мөлкәтне арендага бирүне килештерергә;

2) мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тартырга.

7. Мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) мөлкәтне арендага бирү муниципаль мәдәният оешмасы эшчәнлеген нәтиҗәлерәк оештыруга булышлык итмәячәк;

2) мөлкәтне арендага бирү максатлары муниципаль мәдәният оешмасының уставында каралган эшчәнлек төрләренә туры килми;

3) мөлкәтне арендага бирү элек чиратлылык тәртибендә кергән гаризага карата мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча килештерелгән.

8. Кабул ителгән карар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән рәсмиләштерелә муниципаль мәдәният оешмасына ул кабул ителгән көннән алып 30 көн эчендә җибәрелә.

9. Мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тарту турындагы карарда баш тарту сәбәпләрен нигезләү булырга тиеш.

Мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгәндә, мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар муниципаль мәдәният оешмасына мондый карар кабул ителгән көннән алып 20 көн эчендә кире кайтарыла.

10. Мөлкәтне арендага бирүне килештерү турында кабул ителгән карар мәдәният муниципаль оешмасы тарафыннан мөлкәтне конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә генә арендалау шартнамәсен төзү өчен нигез булып тора.

11. Муниципаль мәдәният оешмасы аренда шартнамәсе төзелгән көннән алып 30 көн эчендә аренда шартнамәсе төзелү турында язма рәвештә Арча муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына хәбәр итә (арендага бирелгән мөлкәт исемлеге һәм аны арендага бирү срогы кушымтасы белән).